КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 21 август г.Казань № 623

2025 – 2029 елларга Татарстан Республикасының тернәкләндерү оешмалары тарафыннан инвалидларны комплекслы реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең кайбер төп юнәлешләре буенча хезмәтләр күрсәтү стандартлары һәм балаларга һәм аларның гаиләләренә иртә ярдәм итү буенча хезмәтләр күрсәтү стандартлары нигезендә инвалидларны комплекслы реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең кайбер төп юнәлешләре буенча чараларны һәм хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыруны башкару буенча күчеш чоры чаралары планын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының тернәкләндерү оешмалары тарафыннан инвалидларны комплекслы реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең кайбер төп юнәлешләре буенча хезмәтләр күрсәтү стандартлары һәм балаларга һәм аларның гаиләләренә иртә ярдәм итү буенча хезмәтләр күрсәтү стандартлары нигезендә инвалидларны комплекслы реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең кайбер төп юнәлешләре буенча чараларны һәм хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыруны башкару буенча күчеш чоры чаралары планын раслау турында» 2024 елның 11 июлендәге 938 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының тернәкләндерү оешмалары тарафыннан инвалидларны комплекслы реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең кайбер төп юнәлешләре буенча хезмәтләр күрсәтү стандартлары һәм балаларга һәм аларның гаиләләренә иртә ярдәм итү буенча хезмәтләр күрсәтү стандартлары нигезендә инвалидларны комплекслы реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең кайбер төп юнәлешләре буенча чараларны һәм хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыруны башкару буенча күчеш чоры чаралары планын эшләү кагыйдәләренең 2 пунктын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2025 – 2029 елларга Татарстан Республикасының тернәкләндерү оешмалары тарафыннан инвалидларны комплекслы реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең кайбер төп юнәлешләре буенча хезмәтләр күрсәтү стандартлары һәм балаларга һәм аларның гаиләләренә иртә ярдәм итү буенча хезмәтләр күрсәтү стандартлары нигезендә инвалидларны комплекслы реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең кайбер төп юнәлешләре буенча чараларны һәм хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыруны башкару буенча күчеш чоры чаралары планын (алга таба – План);

2025 – 2029 елларга Татарстан Республикасының тернәкләндерү оешмалары тарафыннан инвалидларны комплекслы реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең кайбер төп юнәлешләре буенча хезмәтләр күрсәтү стандартлары һәм балаларга һәм аларның гаиләләренә иртә ярдәм итү буенча хезмәтләр күрсәтү стандартлары нигезендә инвалидларны комплекслы реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең кайбер төп юнәлешләре буенча чараларны һәм хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыруны башкару буенча күчеш чоры чаралары планы үтәлешен тәэмин итү чаралары һәм төбәк тернәкләндерү инфраструктурасы исемлеген.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы инвалидларны комплекслы реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең кайбер төп юнәлешләре, балаларга һәм аларның гаиләләренә иртә ярдәм итү буенча хезмәт күрсәтүче Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренә Планның үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Инвалидларны комплекслы реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең кайбер төп юнәлешләре, балаларга һәм аларның гаиләләренә иртә ярдәм итү буенча хезмәтләр күрсәтүче дәүләткә карамаган оешмаларга План чараларын үтәүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 15 февраленә кадәр, Планның үтәлеше турындагы мәгълүматны Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин